**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№752**
**18.02.2022**

Башкарма комитет карарлары
үз көчен югалтуны тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Челнинские известия» газетасының 2018 елның 26 декабрендәге 94 санында, 2019 елның 16 гыйнварындагы 2 санында, 2019 елның 18 гыйнварындагы 3 санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 19 октябрендәге 6260 номерлы;

2) «Челнинские известия» газетасының 2019 елның 6 декабрендәге 90 санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2018 елның 19 октябрендәге 6260 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 6263 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов